Альметьевский вестник

юбилей уңаеннан

Фәридә Исмәгыйлова: "Яхшылыкларны саклап, бүгенгене кабул итеп яши белергә кирәк"

Гаярьлеге, тырышлыгы, таланты белән тормыш дилбегәсен кулына нык тотып балкып яшәүчеләр бар. Аларның энергиясе, куйган максатларга омтылышы, фикер яктылыгы һәркемне үзенә тарта. Агымдагы Мәдәният елында 70 еллык юбилеен билгеләп узачак Әлмәт татар дәүләт драма театры белән соңгы 9 елда җитәкчелек итеп, аны бүгенге югарылыкка күтәрүгә үзеннән лаеклы өлеш кертүче ТР атказанган укытучысы, ТР атказанган мәдәният хезмәткәре, Р.Төхфәтуллин премиясе лауреаты Фәридә ханым Исмәгыйлова шундый затлы шәхесләрнең берсе.

Туган көне январь аеның беренче числосында ук булып узса да, мин килеп кергәндә кабинет әле чәчәк букетларыннан арынмаган иде. "Коллективым бүләк итте",- диде юбиляр минем сорау катыш соклану белән 55 ак розадан торган букетка төбәлгән карашымны аңлап. Аның шулай яратып, горурланып "үземнекеләр" дип әйтүе дә җитәкче белән коллектив арасындагны бердәмлекне, аларның бер дулкында эшләвен, иҗат итүен күрсәтә. Юбиляр белән әңгәмәбез хезмәт, иҗат, тормыш хакында.

- Фәридә Бәгыйсовна, юбилейларга аеруча бай 2014 елга аяк бастык. Нефтьчеләр каласының рухи, мәдәни үзәге булган театр белән җитәкчелек итәргә туры килер дип уйлаганыгыз бар идеме?

- Чыннан да, юбилейлар елын җиңел аягым белән үзем ачып җибәрдем. Зур бәйрәмнәр әле алда көтелә. Январьның 18 ендә театрның примадоннасы Луиза Солтановага 70 яшь тула, 20сендә Фәһимә Бикмуратованың 50 яшьлек юбилее. Театр белән җитәкчелек итүгә килгәндә, гимназиядән китү җиңел булмады, әлбәттә. Шулай да, күңел каядыр җилкенде, яңалыкка омтылды. Мин бертөрлелек яратмыйм. Театр директоры вазифасын тәкъдим иткәч тә, башта каршы килдем. Әлеге эшнең авырлыгын, катлаулылыгын чамалап булса да белә идем. Алынгач, булдыра алганча тырышабыз инде.Театрның 70 еллыгы белән бәйле планнарыбыз да зурдан. Күңелне иң сөендергәне, Яңа ел котлавында район башлыгы Мәҗит Хаҗипович Мәдәният елы турында сөйләгәндә, иң беренче булып, театрның 70 еллыгын билгеләп узачакбыз, диде. Ялгыз түгел икәнбез дип уйладым, күңелгә җылы кереп, ышаныч барлыкка килде.

Яңа елның тагы бер сюрпризы, моңа кадәр Яңа елга биналарны бизәгәндә үз көчебезгә генә таяна идек. Ә быел безгә әйтеп тә тормыйча, күтәртә торган машиналар белән килеп, бинаның фасадын матур итеп бизәп киттеләр. Театрның утлары ерактан балкып, күренеп тора. Әллә шуның шаукымы, тамашачыларыбыз да көннән-көн арта. 70 нче сезонны сентябрь аенда ачарга исәплибез. Теләгем, Фәрит Бикчәнтәев режиссерлыгында саллы гына бер классик әсәрне сәхнәләштерү. Октябрь аенда Луиза Солтанованың юбилей кичәсен уздырып, театрда яшьләр, балалар көннәре кебек аерым проектлар оештыру күздә тотыла. Күңелне борчыган әйберләр дә бар, билгеле. Соңгы елларда мин театрда җитәкчеләрне югалттым. Предприятие, депутатлар корпусы турында сүз бара. Алар тарафыннан театрга ваксынып карау кебек мөнәсәбәт сизәм. Алар өчен дә аерым бер көн уздыру планы бар. Җитәкче күпкырлы да булырга тиеш. Мәдәнияткә, сәнгатькә катнашы булмаганнар да театрны яратырга, хөрмәт итәргә тиеш, дип уйлыйм.

- Сез Әлмәттә беренчеләрдән булып татар гимназиясен ачкан кешеләрнең берсе. Дистә елга якын мәдәният учагын яңа югарылыкка күтәрүгә хезмәт итәсез. Каян килә Сездә мондый миллэтпәрвәрлек ?

- Ул балачактан. Әтием дә, әнием дә бик милли җанлы кешеләр. Алар миңа татар моңын сеңдереп үстерделәр. Әтием мәктәптә эшләгәндә үзе сценарийлар төзи, шигырьләр яза иде. Әнием исә тирә-якта танылган бер җырчы. Әти аның тавышына, җырлавына гашыйк булып өйләнгән. Аның башкаруындагы "Салкын чишмә", " Хуш, авылым" җырларын тыңлаганда үзәкләр өзелерлек. Әни булган өчен әйтмим, бу чыннан да шулай иде. Хәзер аңа 91 яшь, кызганычка каршы, 50 яшендә тавышы бетте. Ике апам бар, берсе миннән 18, икенчесе 10 яшькә өлкән. "Син капка баганасына сөялгән, авыз эченнән әкрен генә нәрсәдер көйләгән килеш күз алдында торасың", - диләр алар. Кечкенә чагымда тере, хәрәкәтчән бала түгел идем мин. Чаңгы шуып, туп артыннан йөгергәнемне дә хәтерләмим. Күп вакытым китап укып, радиодан җырлар тыңлап уза иде.

- Әлмәтлеләрнең күпчелеге Сезнең башкарудагы җырларны яхшы хәтерлиләр. Хәзер моңланырга вакытыгыз каламы?

- Сәхнәләрдән җырламаганга күптән, билгеле. Шулай да, күңелдә моң бар, ул яши, вакыт-вакыт ургылып тышка чыга. Нинди генә кичәдә булсам да, "Җанкай-җанаш"ны җырлавымны сорыйлар. "Бичура" спектакленнән "Сагыш" җырын, "Шахта" көен бик яратам. Аның авторы Азат Хөсәенов берничә тапкыр әлеге җырны яздырырга да тәкъдим ясады. Рәис абый Нәгыймов исән чагында оркестр белән бергәләп "Авылым" җырын яздырган идек. Мин аны кадерле ядкәр итеп саклыйм.

- Балачактан юрист булырга хыялланганс ыз. Ни өчен мәдәният институтына укырга керергә булдыгыз?

- Миндә бит әллә ничә "мин" яши. Мавыгучанлыгым да көчле. Бер юнәлештән икенчесенә җиңел күчәм. Театр белән кызыксыну, сәхнәләрдә уйнап йөрү профессия итеп сайларга этәргеч биргән, күрәсең. Тормыш тоташ боҗра кебек, хәзер менә киредән шушы өлкәдә хезмәт итәм. Ә юрист булу хыялын мин өлешчә булса да тормышка ашырдым, соңрак булса да укып, диплом алдым. Җитәкчелек эшендә бик тә ярдәм итә.

- Язмышның алдан сызган юлдан баруына ышанасызмы?

- Төп мәсьәләләрдә, әлбәттә, ышанам. Кеше холкына нинди айда, нинди йолдызлык астында тууның да күпмедер йогынтысы бардыр, дип уйлыйм. Ләкин барлык уңышларны да, уңышсызлыкларны да бер Ходайга гына сылтап калдыру дөрес түгел. Язмыш юлыннан читкә дә тайпылырга мөмкин, мәсьәләне башкача да хәл итеп була. Күпчелек детальләр үзеңнән тора.

- 55 яшь – гомер уртасы, диләр. Артка еш борылып карыйсызмы?

- Бик карамаска тырышам. Әнием гомер буе җырчы булмаганлыгына үкенеп яшәде. Аның бик үзәккә үткән вакытлары бар. Аның мисалында мин үкенмәскә өйрәндем. Күпчелек бүгенге көнгә, иртәгегә карап яшим. Хисле булсам да, мин бик реалист. Авыр мизгелләрдә Скарлетт образы ярдәмгә килә. Берничек тә хәл ителмәсә, гел чарасыз булганда, "Бу хакта мин иртәгә уйлаячакмын", дип үземне тынычландырам һәм шулай эшлим. Еллар узу белән тәҗрибә дә арта, акыллы китаплар да укырга тырышабыз. Без ике заманда тәрбияләнгән кешеләр. Ул чорларның яхшылыкларын саклап, бүгенгене кабул итеп, берләштереп яши белергә кирәк.

- Сәяхәт итәргә яратуыгызны беләм. Кайсы чит илләр аеруча ошады?

- Әйе, мөмкинлек табып чит илләрдә булырга тырышам. Испания, Чехия, Греция, Гарәп Әмирлекләре һәм тагын берничә илдә булдым. Аеруча ошаганы Испания һәм Чехия. Бирeдә архитектура һәйкәлләре үзенчәлекле, халыкның мәдәният дәрәҗәсе югары булу игътибарны җәлеп итә.

- Машина йөртергә теләгегез юкмы?

- Машина йөртү теләге яшьтән үк бар иде һәм мин аны тиз арада тормышка ашырдым. 1994 елда мин руль артына утырганда Әлмәттә әле бик сирәк хатын-кыз машина йөртә иде. 5-6 елдан соң, кинәт кенә курку хисе барлыкка килгәч, әлеге шөгыльне ташладым. Ул минем өчен түгел.

- Сезнең хезмәт кешеләргә бәйрәм ясау белән бәйле. Үзегез нинди бәйрәмнәр яратасыз?

- Шау-шулы, массакүләм чаралардан арылган инде. Минем өчен үзем яраткан, хөрмәт иткән кешеләр белән сөйләшеп утыру, аралашу бәйрәм. Үзебезчә, милли, җылы кичәләрне, театр ачылу сезонын яратам. Кемнәрдер ялгызлыктан интегә, миңа еш кына ялгыз калып уйлану, теләгән китабыңны уку, ирек, азатлык хисе тою бәйрәмгә тиң.

- Кызыклы әңгәмәгез өчен рәхмәт, Фәридә Бәгыйсовна. Коллектив, газета укучыларыбыз исеменнән гомер бәйрәмегез белән тәбрик итәбез. Милләтебезнең рухын баетуга юнәлдерелгән эшегездә иҗади уңышлар, сәламәтлек, тормыш ямен, яшәү шатлыгын тоеп яшәвегезне телибез.

Фәрдия Хәсәнова

яшәеш

Габдрахманда мәдәнияткә юл ачык

Җиһанга 2014 ел аяк басты. Зәңгәр ат елы Мәдәният елы дип игълан ителде.

Узган 2013 ел мәдәният йорты өчен вакыйгаларга бай булды. Январь башыннан ук "Авылым йолдызлары" җыр һәм бию ансамбленең 30 еллык юбилее уңаеннан, күрше тирә авылларда гастрольләр оештырылды, нефть төбәгенең күренекле "Ромашкино", "Бәкер" шифаханәсендә куйган концертлар да сагынып сөйләрлек бер мизгел.

Узган ел Р.Төхфәтуллин исемендәге әдәби бүләккә лаек булган "Сәрбиназ" ансамбле артистлары да мәдәният йортының уңышларында саллы урын алып торуларын горурланып сөйләделәр."Май аенда без легендар җырчыбыз Илһам Шакировның туган ягы Тукай районы, Бүләк авылында узган "Халык моңы - Илһам" фестивалендә катнашып, диплом һәм кыйммәтле бүләкләр алып кайттык. Илһамның төп йорты каршында истәлеккә фотоларга төштек" - дип уртаклашты үзенең сөенечләре белән ансамбльнең өлкән җырчысы Хәтимә апа.

Габдрахманда 25 ел авыл советы рәисе булып эшләгән, бүгенге көндә ветераннар оешмасы җитәкчесе Наҗия Мәүлетбаева турында да сөйләп китми мөмкин түгел. Хәзер дә ул авылыбызның өлкән кешеләре белән зур эш алып бара, җәй айларында Бөек Болгарга сәяхәткә барып кайттылар, мәдәният йорты белән берлектә кызыклы чаралар оештыралар. Август аенда Әлмәт шәһәре һәм районы башкарма комитеты инициативасы, ТР Дәүләт советы депутаты Шәфәгать Тәхаветдинов булышлыгы белән, Габдрахман мәдәният йортында авылыбызның мөхтәрәм кешесе, ТР атказанган мәдәният хезмәткәре Наҗия Шәмсулловнаның 75 яшьлек юбилей кичәсе узды.

Авылның мәдәният йорты җитәкчесе Сәрия Лукошкова билгеләп узганча, 2013 тарихка зур

төзелешләр елы буларак та кереп кала. Нефтьчеләребез булышлыгы белән мәдәният йорты бинасына өстәп бүгенге көн таләпләренә җавап бирелек югарылыкта янкорма төзелә, кыйммәтле спорт тренажерлары урнаштырыла. Бүгенге көндә авыл халкы калада яшәүчеләр көнләшерлек шартларда яши. Ял вакытларын файдалы үткәрү, сәламәт яшәү рәвешен алып бару өчен бөтен мөмкинлекләр дә тудырылган. Хәзерге вакытта спорт комплексында ТР атказанган спорт мастеры, көрәш буенча дөнья чемпионы Руслан Ришат улы Нургалиев татарча көрәш секциясе алып бара. Яшьләр дә, балалар да бик теләп йөри, авыл халкы Руслан Ришат улына бик рәхмәтле.

Авыл китапханәсе авыл яшьләрен тәрбияләүдә зур эш алып бара. Китапханә мөдире Ләйлә Кадыйрова төрле темаларга дискуссияләр оештыра, авылның участок инспекторы һәм баш табибы һәрдаим хәзерге заман өчен актуаль темаларга чыгыш ясыйлар.

Мәдәният йорты зур бәйрәм концертлары оештыра, 8 Март, 23 февральгә багышланган чаралар аншлаг белән уза. Башка еллардан аермалы буларак, быел мәдәният йорты каршында урнаштырылган чыршының ачылу тантанасы күркәм бәйрәмгә әверелде. Чарада авыл халкына, яңа ел бәйрәмнәре белән тәбрикләү сүзләрен ТР Дәүләт советы депутаты Ш.Ф. Тәхаветдинов исеменнән аның ярдәмчесе Рөстәм Гарипов җиткерде. Бизәлгән җигүле ат кунакларны Совет урамы буйлап йөртте. Кыскасы, бар да бик югары дәрәҗәдә, күңелле мизгелләр булып калырлык оештырылган иде.

Авыл җирлеге Советы, мәдәният йорты, китапханә барлык социаль учреждениеләрнең бергәләп ел дәвамында башкарган эшләре мактауга лаек. Клуб тамашачылар белән тулы заллар җыя ала икән, димәк, тәрбия эше тиешенчә оештырыла. Мәдәният йорты җитәкчесе Сәрия Лукошкова тырыш хезмәте өчен "Әлмәт шәһәренә 60 ел" юбилей медале белән бүләкләнде.

Мәдәният йортының 2014 елга уйланган планнары да зурдан, аларга уңышлар телибез.

Айдар ГАЗИЗУЛЛИН
Автор фотолары